# *“Синең хөрмәтле мөгаллимнәрең, туган мәктәбем!”*

### *“Колагымда һаман кыңгыраулар чыңлый”*




*Ветеран укытучылар Зәйнуллина Ф.Г. һәм Аюкина Р.Т.*
*шефлык итүче 1б класс җитәкчесе Шәрифуллина З.В. белән*

Һөнәрләрнең ниндиләре генә юк! Һәр кеше үзенә якынын сайлап ала.Минем язмам һәр һөнәрнең дә башлангыч нигезе булган укытучы һөнәре, ярты гасырга якын гомерен балалар тәрбияләүгә багышлаган Зәйнуллина Фәһимә Гыйльмиевна турында.

2016 нчы елның 15нче августында аңа 92 яшь тула.Фәһимә Зәйнуллина - унынчы дистәсен ваклаганда да, күпләргә киңәшче, сөйләгәнен тыңлап туймаслык акыл иясе, балаларына, оныкларына терәк-таяныч булырлык әни һәм дәү әни.

Фәһимә Гыйльми кызы Мулланур Вахитов исемендәге 2 нче татар мәктәбендә 26 ел география укыта. География - кызыклы һәм мавыктыргыч фән. Алабуга педагогия институтының биология – география факультетын бик яхшы билгеләренә генә тәмамлаган педагог үз фәнен укучыларына да яраттыра ала. Дәрестә алган

белемнәрен бaету максатыннан, укучылар туган як буйлап экспедицияләргә, походларга чыгалар, авыл кешеләренә концертлар күрсәтәләр; кайткач, фәнни – гамәли конференцияләр үткәрәләр. Ветеран укытучының альбомында әлеге чаралардан бик күп фоторәсемнәр саклана.



*Фәһимә Гыйльмиевнаның укучылары походка чыгар алдыннан*

1969-1970 нче уку елында 2 татар мәктәбе яңа бинага күчкәч, татар сыйныфлары белән беррәттән рус сыйныфлары да ачыла. 1957-79 нчы елларда сыйныф җитәкчесе булып эшләп, Фәһимә Гыйльмиевна өч класс чыгара.

Фәһимә Гыйльмиевна шул вакыттагы бер хәлне еш искә төшерә: “Ул вакытта мәктәп директоры булып бик авторитетлы Кутузов М.Т эшли иде. Беркөнне ул мине чакырып алды да уку-укыту эшләре буенча мөдир булып эшләргә тәкъдим итте. Ләкин мин аның үтенечен кире кактым,сәбәпләрен аңлаттым. Сәбәпнең иң зурысы - балалар белән эшлисе килү иде. Үз фәнемне яратып укыттым, балаларда да кызыксыну уяттым. Ләкин минем өчен иң рәхәте - балалар белән, сыйныф белән эшләү булды,“ - дип искә ала Фәһимә Гыйльмиевна.

Ветеран укытучы үзе белем биргән һәр укучысын хәтерендә тота, һәрберсенең исемен,фамилиясен, буен, чәчен, холкын исенә төшереп сөйли. Фоторәсемнәр актарганда, сыйныфтагы иң озын буйлы егет, нәфис гәүдәле кыз, рәссам малай, оялчан егет иде, дип укучыларын яратып искә төшерә,аларның кайсы институтны бетерүләре, кайда яшәүләре турында сөйли, фаҗигале язмышка очраганнарын күз яшьләре белән искә ала.

60-80 нче елларда сыйныф җитәкчелеге өчен бер тиен дә хезмәт хакы түләнмәгән. Һәр укытучы намусы кушканча Туган ил, мәктәп өчен , балалар чын кеше булып үссеннәр өчен эшләгән. Фәһимә Гыйльмиевна шул еллардагы эшләрен бернинди зарланусыз, кызык хәл сөйләгән кебек кенә итеп искә ала: "Һәр елны кол-хозга көл җыеп тапшыра идек. Балалар Орловка авылының һәр өенә, мунчасына кереп, мичләрен "чистартып" чыгалар иде." Ә бу эшләрне оештыру өчен хезмәтне ярату, сабыр булу, вакытыңны кызганмау кирәк.




*Ярышта җиңеп чыккан укучылар белән Казан шәһәренә экскурсиягә баргач. Уртада - география укытучысы Зәйнуллина Фәһимә Гыйльмиевна һәм татар теле һәм әдәбияты укытучысы Җамалиева Бәһрия Камалиевна*



.

*Мәктәп директоры Уразаев И.Т. һәм класс җитәкчесе Зәйнуллина Фәһимә Гыйльмиевна 1978-1979 нчы уку елы чыгарылыш класс укучылары арасында. Беренче рәттә уңнан өченче “ КамАЗ- мастер” экипажының бортмеханигы, “Халыклар дуслыгы” ордены кавалеры Баһаветдинов Наил Мансур улы*

Мәктәптә бергә эшләгән хезмәттәшләрен бик җылы хисләр белән искә төшерә мөхтәрәм педагог. Бергә эшләгән укытучылар Фәрдиева Гөлсинә Фәрдиевна, Вальтеева Ләлә Хәкимовна, Гумеров Хәниф Гарипович, Сәгыйтов Зөфәр Яруллович, Рәшидә Гайнулловна, Дәүләтшин Гафинур абыйларны олы хөрмәт белән һәм сагынып искә ала.Укытучылар бик тә зыялы, тырыш булу белән бергә шәһәрдә югары культураны таратучылар булды, ди ветеран укытучы. Фәһимә Гыйльмиевна коллективның демонстрациягә чыгуларын болай искә ала: ”Директор булып Нәкый Шәйхетдинович эшләгәндә директордан башлап бөтен укытучы диярлек заманча тегелгән яхшы пальто кия башладылар.Шәһәр халкы демонстрациягә чыкканда, 2 нче мәктәп коллективын күрергә чыгабыз,алар үтеп киткәч кенә кайтып китәбез,”- дия торган булганнар. Ул кайсы укытучы нинди фасонлы, нинди төстәге киемнән йөрүенә чаклы хәтерли.

Фәһимә Гыйльмиевна гаделлек,мәрхәмәтлелек, кешелеклелек кебек сыйфат-ларны укучыларының күңелләренә сеңдергән,тормыш юлын абынмый үтәрлек чын кешеләр тәрбияләгән. Мәктәпне тәмамлап киткән укучылар белән очрашуны да уку йортында беренчеләрдән булып ул башлап җибәргән һәм аларның тулы класс белән килүләрен тәэмин иткән. Укытучы бүген дә укучылары белән аралашып, аларның шатлыкларын, борчуларын уртаклашып, зирәк киңәшләрен биреп яши.

Безнең 2 нче гимназиядә матур традиция яшәп килә. Елга берничә мәртәбә ветеран укытучыларыбыз кыңгырау чыңы яңгырап торган гимназиягә җыела. Гимназия директоры Аюпова Фирдүсә Фәнәвисовна, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Харисова Энҗе Мирзануровна, сыйныф җитәкчеләре, укучылар кунакларның килүен зур әзерлек һәм дулкынлану белән көтеп ала. Мәктәпнең түренә узганда, өлкән мөгаллимнәребезнең күзләрендә сабырлык, йөзләрендә татар мәктәбе өчен горурлык һәм канәгатьләнү хисләре чагыла. Мондый очрашуларга Зәйнуллина Фәһимә Гыйльмиевна бик теләп, кыңгыраулар чыңын сагынып килә. Бу көннәрдә 2 нче гимназия коллективы мәктәпнең 110 еллык юбилеен үткәрүгә зур әзерлек алып бара. Фәһимә Гыйльмиевна, һич авырсынмый, гимназиягә килә, кадерле истәлекләре

белән уртаклаша, укучы-ларын барлый. 21 апрель көнне гимназия коллективы “КамАЗ- мастер” да илгә дан китергән укучылары белән очрашачак. Алар арасында Фәһимә Гыйльмиевнаның яраткан укучысы Наил Баһаветдинов та булу - ветеран өчен зур сөенеч!

Зәйнуллина Фәһимә Гыйльмиевнаның хезмәте югары бәяләнгән. Ул шәһәр мәгариф идарәсе тарафыннан бик күп Мактау грамоталары белән, “Социалистик ярышта җиңүче” билгесе белән бүләкләнгән, исеме шәһәр мәгариф идарәсенең Мактау китабына кертелгән.

Ул тәрбияләгән укучылар һәрвакыт укытучыларын турында матур хәтирәләр генә саклыйлар. 1966 нчы елгы чыгарылыш класс укучылары укытучыларын туган көн белән котлап түбәндәге сүзләрне язганнар: Мөхтәрәм Фәһимә Гыйльмиевна! Сез Чаллы каласында туып үскән меңләгән укучыларның география укытучысы гына түгел, ә яраткан укытучысы - тыңлый белүче, акыллы иптәш, юнәлеш бирүче нечкә психолог. Сезнең гаҗәеп төгәллегегез,алдан күрә белеп,оста оештыруга сәләтегез бик күп укучыларыгызның һөнәри язмышына уңай йогынты ясады, дәрт бирде, өлге булды”.

Фәһимә Гыйльмиевнаның гаилә тормышы да үрнәк. Тормыш иптәше Расим абый белән 56 ел бергә сокланырлык гомер иткәннәр алар. ”Миңа яшәү өчен иң күп көчне бирүче Ходай Тәгалә һәм ирем булды.Эштә борчылган чакларымда мине юатучы булды, улымның һәм кызымның сөекле әтиләре ул иде.Төпле акыллы ирем, тәртипле балаларым булганга, мин эшемә күңел биреп, хезмәтем-нән җан азыгы алып эшләдем”,- ди Фәһимә Гыйльмиевна.

Фәһимә Гыйльмиевнаның тормыш юлы турында ахыры матур тәмамлана торган роман язарлык. Шушы юлларны язганда, күңелгә шигырь юллары килә:

Фәһимә Гыйльми кызы ул

Укытучы апабыз.

Зурлыйбыз,хөрмәт итәбез,

Һәммәбез яратабыз.

Күпме укучы үз иткән

География фәнен.

Сизми калган хезмәттә

Ярты гасыр үткәнен.

Гимназиянең дусты ул.

Чып-чын гыйлем иясе.

Сезгә зур ихтирам белән

Килә башны иясе.

2 нче гимназиянең югары категорияле ветеран

*укытучысы Шәрифуллина Зөһәйрә Вахидиновна*